**ТР ФА Ш.Мәрҗани ис. Тарих институты**

**Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге**

# Укучыларның туган төбәкне өйрәнү буенча фәнни-эзләнү эшләрен оештыру

## Методик ярдәмлек

Казан – 2014

**Укучыларның туган төбәкне өйрәнү буенча фәнни-эзләнү эшләрен оештыру: Методик ярдәмлек.** – Казан: Ш.Мәрҗани ис. Тарих институты, 2014

**Авторлар коллективы:**

Абызова Р.Р., Әхтәмова А.В., Биктимирова Т.Ә., Миңнуллин Ф.Г., Мөхәммәтҗанова Д.С., Садыков Ш.Ф., Сафина А.М., Сафиуллина Р.Р.

**Төзүчеләр:**

М.М. Гибатдинов (җаваплы редактор), Л.Р. Мортазина

# Эчтәлек


Кереш ..... 4

Эзләнү эшенең темасын сайлау һәм материал туплау ..... 5

Укучыларның фәнни-эзләнү эшләренә таләпләр ..... 6

Туган як тарихын өйрәнүдә төп чыганак
булларак архив документлары ..... 14

Гаилә тарихын һәм төбәкнең тарихи шәхесләрен өйрәнү ..... 17

Тарихи һәм табигый һәйкәлләр ..... 20

Төбәкнең мәдрәсә, мәчет-мәхәллә тарихын өйрәнү ..... 22

Туган як тарихын өйрәнүдә топонимиканың роле ..... 25

Туган төбәкне өйрәнү материалы буларак фольклор ..... 27

Тәкъдим ителгән әдәбият ..... 29

Кушымта ..... 35

# Кереш

Татарстан Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗәни ис. Тарих институты Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә 2003 елдан бирле даими рәвештә татар халкы һәм Татарстан тарихы буенча республика (2013/2014 уку елыннан – төбәкара) конкурсы уздыра. Конкурста Татарстан республикасы һәм Россия төбәкләренең гомуми урта белем бирү мәктәпләренең 8-11 сыйныф, шулай ук башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү оешмалары укучылары катнаша ала. Конкурсның төп максаты – укучыларда туган як тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүгә кызыксындыру тудыру; тарихи чыганаклар белән эшләү күнекмәләре булдыру; тарих фәнен өйрәнүгә сәләтле укучыларны барлау һәм милли белем бирүне камилләштерү, үстерү; ватанпәрвәрлек, толерантлык һәм әхлакый идеаллар тәрбияләү. Конкурс ике этапта уза. Җиңүчеләргә дипломнар һәм истәлекле бүләкләр тапшырыла. Иң яхшы дип табылган эшләр Ш.Мәрҗани ис. Тарих инситутында дөнья күрүче басмаларга тәкъдим ителә.

Конкурсның II турына жюри тарафыннан җентекле рәвештә сайлап алынган эшләр тәкъдим ителә. Иң беренче чиратта эзләнү эшләренең эчтәлегенә, тарихи материалның бирелешенә, шулай ук фәнни аппарат эшләнешенә игътибар бирелә. Тасвирлама характердагы эшләр конкурска кабул ителми (Конкурсның шартлары турында тулырак www.tataroved.ru сайтыннан карарга мөмкин).

Әлеге методик әсбап Татар халкы тарихы һәм мәдәнияте буенча конкурста катнашучы укучыларга һәм аларны әзерләүче укытучыларга фәнни-эзләнү эшләрен оештыруда һәм уздыруда ярдәмлек буларак төзелде.

## Эзләнү эшенең темасын сайлау

Фәнни-эзләнү эше Татарстан, татар халкы һәм туган төбәк тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүгә багышланган конкурска тәкъдим ителгән юнәлешләрнең берсе буенча (кара: www.tataroved.ru) тема сайлап алудан башлана. Ләкин нинди генә тема алынса да, башкарылган эштә укучының мөстәкыйль һәм эзлекле фикерләве, яңалыгы игътибар үзәгендә булырга тиеш. Укучыдан беренче чиратта төрле чыганакларны өйрәнү, анализлау нәтиҗәсендә сурәтләнелгән тарихи вакыйга һәм фактларга карата үз фикерен әйтә белү сорала.

Эзләнү эше өчен тема эзләгәндә төрле чыганакларга мөрәҗәгать итәргә: әти-әни, әби-бабай, төбәк тарихыннан хәбәрдар булган өлкәннәрдән сораштырырга, гаилә, мәктәп һәм шәһәр (район) архивларында эзләнергә, иске газета-журналларны актарырга мөмкин. Күп очракта үзегез өчен кызыклы булган, эзләнү эшенә этәргеч бирердәй материалларны мәктәп, авыл, шәһәр музейларыннан да табып була. Мемориаль такталар, урам исемнәре, борынгы биналар, шулай ук туган төбәк тарихын яктыртучы фотоальбом, китап һәм башка җыентыклардагы рәсем яки мәкаләләр да тема сайлауда ярдәм итәргә мөмкиннәр.

Яңа мәгълүматлар белән баету мөмкинлеге булмаган очракта яхшы билгеле, өйрәнелгән атаклы шәхесләр яки тарихи вакыйгаларны эзләнү эшенең темасы итеп алырга ярамый. Шуңа күрә теге яки бу теманы сайлаганчы туган якны өйрәнү музее хезмәткәрләре, вуз укытучылары белән киңәшләшергә кирәк.

Тикшерү объектын якыннан өйрәнү өчен иң беренче аны фотога төшерү һәм һәр фотоның төгәл исемен теркәп кую мөһим. Болай эшләү алга таба материалны эшкәртү барышында уңайлыклар тудырачак.

Иң мөһим этапларның тагын берсе – тема буенча фәнни әдәбият эзләү һәм аны өйрәнү. Моның өчен китапханәдә булган туган як тарихына

багышланган китап, җыентык, белешмәлекләр, журнал һәм газеталарны карап чыгарга, аерым шәхесләргә багышланган мәкаләләрне туплаган каталоглар белән эшләргә өйрәнергә кирәк.

Өлкәннәрдән, күршеләрегездән теге яки бу бинаның төзелү, үзгәртеп корылу тарихы турында сорагыз, алар сөйләгәннәрне диктофонга язып алыгыз, мөмкинлек чыгу белән эшкәртеп, кәгазьгә күчерегез, ике вариантны да саклагыз. Бу әңгәмәләр вакытында тупланган материал сезнең эшегездә бик кыйммәтле чыганак ролен үтәргә мөмкин, ләкин аларның дөреслеккә туры килү-килмәүләрен тикшерү мәҗбүри.

Фәнни-эзләнү эшләрен башкаруда иң мөһим чыганакларның берсе – архив материаллары. Аларны эзләү, анализлау һәм эшегездә дөрес һәм урынлы итеп файдалану мөһим (Бу турыда тулырак итеп “Туган як тарихын өйрәнүдә төп чыганак буларак архив документлары” дигән бүлектән укыгыз). Эзләнү эшләре барышында моңарчы дөнья күрмәгән хатирәләр, хатлар, көндәлекләр дә файдаланырга мөмкин.

Иң беренче чиратта укучылардан һәр документны җентекләп өйрәнү һәм анализлау таләп ителә. Конкурс эшләрен бәяләгәндә, тарихи материал һәм укучының үз фикерләрен җиткерә белүе белән беррәттән, бу мәсьәләгә дә зур игътибар биреләчәк.

## Укучыларның фәнни-эзләнү эшләренә таләпләр

Мәктәп укучыларының татар халкы һәм Татарстан тарихы, мәдәнияте белән кызыксынулары татар халкы тарихы һәм мәдәнияте буенча үткәрелгән конкурс эшләренең эчтәлегендә дә чагылыш таба. Укучылар үзләренең фәнни-эзләнү эшләрендә, күпсанлы тарихи чыганакларга таянып, халкыбызның бай матди һәм рухи мирасын барларга, тулыландырырга һәм югалтмаска омтылалар, фәнни телдә эш башкару алымнарына өйрәнәләр.

Әмма укучыларның эшләрендә еш кына фәнни стильдән читләшү, аның таләпләрен үтәмәү күренешләре күзәтелә.

Билгеле булганча, фәнни стиль чынбарлыкны танып-белү өчен формалаша, теге яки бу фән өлкәсенә кагылышлы кануннарны барлый. Шулар аша яшәешне аңларга һәм аңлатып бирергә ярдәм итә торган хосусый төшенчәләр һәм аларның телдә чагылыш тапкан атама-терминнары ярдәмендә фикерне логик эзлеклелектә ачык, аңлаешлы, дәлилле, объектив бирүне күздә тота. Шул сәбәпле фәнни-тикшеренү эшләрендә фән теленә хас булган үзенчәлекләр һәм билгеле бер кагыйдәләр үтәлергә тиеш. Аларның аеруча мөһим булганнарына тукталып үтик.

**Язмаларның фәнни эшләнеше, ягъни эшнең фәнни-техник һәм стилистик структурасы.** Эш, нигездә, 3 бүлектән тора: кереш, төп өлеш, йомгак. Аннан соң кулланылган әдәбият исемлеге (библиография) һәм кушымталар теркәлә.

Иң беренче чиратта фәнни-эзләнү эшенең титул битенә игътибарлы булырга кирәк. Чөнки шушы биттән үк укучының йөзе, аның үз хезмәтенә мөнәсәбәте, грамоталылыгы күренеп тора. Адресатларны, мәктәп атамаларын күрсәткәндә, башкаручының һәм җитәкченең исем-фамилияләрен язганда хаталар һәм ике телдә язылышны калдырырга ярамый.

Күп очракта укучылар, мәктәптә язган иншаларга ияреп, фәнни эшләрен башлаганда эпиграфлар китерәләр. Бик мәгънәле һәм хезмәтнең эчтәлегенә туры килсә дә, иҗади эшләргә хас булган эпиграфларны фәнни-эзләнү эшләрендә файдалану тыела.

Фәнни-тикшеренү эшенең кереш өлешендә теманың яңалыгы, актуальлеге, максат һәм бурычлары, фактик материал һәм чыганаклар белән эшләүнең төрле алымнары һәм методологиясе бәян ителә; өйрәнелә торган темага кагылышлы фәнни әдәбиятка кыскача күзәтү ясала.

Төп өлеш, теманы тикшерү – өйрәнүнең күләме һәм структурасы белән бәйләнешле рәвештә төрле бүлекләрдән һәм бүлекчәләрдән торырга мөмкин. Аларның эчтәлеге билгеле бер өзлеклелектә фактик материалларны мөстәкыйль өйрәнү һәм анализлау, фәнни әдәбияттан һәм чыганаклардан дөрес файдалану рәвешендә бара. Өйрәнелә торган тема буенча башка авторларның фикер-карашларын бирүгә аеруча игътибарлы булырга кирәк, чөнки аларны үзеңнеке итеп күрсәтү, фәнни урлашуга (плагиатлыкка) керә. Авторлык хокукларын саклау турындагы закон нигезендә плагиатлык өчен җаваплылык каралган. Шуңа күрә фәнни чыганактан китерелгән өземтә (цитата) һәр очракта төгәл һәм дөрес күрсәтелергә тиеш.

Мәгълүм булганча, өземтәне кулланучы автор берничә максатны күз алдында тота: 1) үз фикереңне башка кеше сүзләре белән ныгыту; 2) башка автор тарафыннан әйтелгән фикерләрне киңәйтеп аңлату яисә тәнкыйтьләү.

Өземтә итеп алынган башка кеше фикерләре сүзгә-сүз, курсивлар һ.б. үзенчәлекләре белән анык китерелергә һәм, барыннан да бигрәк, цитата алынган хезмәтнең эчтәлеген бозып күрсәтмәскә тиеш. Чөнки контекстан өзеп алынган җөмлә яки аның кисәгенең мәгънәсе, аерым кулланган очракта, хезмәттә (әсәрдә) үткәрелгән фикердән аерылырга да мөмкин. Моннан саклану өчен, төп нөсхәдән алынган өземтәне һичнинди үзгәртүләрсез бирергә кирәк. Бу – мәҗбүри үтәлергә тиешле таләпләрнең берсе. Шулай ук китерелгән язма текстның өйрәнелә торган теманы ачуда, аны тулыландыруда нигезле чыганак булуын истән чыгармаска кирәк. Шуңа күрә өйрәнә торган темага караган фәнни әдәбиятны, төрле чыганакларны ныклап өйрәнү һәм өземтәләрне дә билгеле авторларның фундаменталь хезмәтләреннән китерү мөһим.

Кайбер очракларда өземтә итеп алынган текст эчендә кыскартулар булырга, аерым сүзләр яки җөмләләр төшереп калдырылырга да мөмкин. Мондый урыннарда күп нокталар куела. Әмма шунысын онытмаска кирәк:

алар өземтәнең тулаем эчтәлегенә, мәгънәви бөтенлегенә зыян салырга тиеш түгелләр.

Туры сөйләм рәвешендә бирелгән өземтә куштырнаклар эченә алына. Бу вакытта туры сөйләмне автор сөйләменә бәйләүче чаралар булып әйтүгә һәм уй-фикер йөртүгә мөнәсәбәтле фигыльләр кулланыла. Аеруча *ди*, *дип*, *дигән*, *әйт*, *уйла*, *яз, аңлат*, *күрсәт* һ.б. сүзләр еш файдаланыла.

Туры сөйләм һәм автор сөйләменең урнашу тәртипләрен белү аеруча әһәмиятле, чөнки шуңа мөнәсәбәтле рәвештә сөйләмнең төзеклеге, логик бөтенлеге саклана, тыныш билгеләренең дөрес куелышы тәэмин ителә.

Иң әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе – өземтә итеп алынган текстның чыганакларын күрсәтү. Гадәттә, ул астөшермәдә (сноскада) бирелә. Астөшермәдә өземтәнең кайдан китерелгәнлеге турында тулы мәгълүматлар бирелә.

Игътибарыгызга астөшермә бирүдә бер үрнәк тәкъдим итәбез.

**Тарихның фәннәр системасындагы урынын билгеләп, Ш.Мәрҗани болай дип әйтә: “Бел, ул – хикмәтләр диңгезенә чумган чын гыйлем һәм башка фәннәрне дә үзара бәйли торган хөрмәткә лаек фән”[1].**

Рус телендәге чыганаклардан алынган өземтәләрне туры сөйләм рәвешендә биргәндә, төп нөсхәдәгечә, ягъни татар теленә тәрҗемә итмичә генә китерү уңышлырак, чөнки тәрҗемә иткәндә, аның эчтәлегенә һәм фикер бөтенлегенә зыян салынырга мөмкин. Мондый очракларда рус телендәге өземтәне кыек сөйләм рәвешендә татарча да биреп була. Ә туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндерү юллары мәктәп дәреслекләрендә шактый тулы яктыртылган.

[1] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар [Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр] Ш.Мәрҗани /төз. Хәйруллин Ә.Н. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 42 б.

Йомгаклау – алып барылган тикшерү-өйрәнүнең кыскача, ачык, төгәл һәм гомумиләштерелгән нәтиҗәсе ул. Аның дәлилле булуына, логик эзлеклелектә бирелүенә аеруча игътибарлы булырга кирәк.

Әдәбият исемлеген (библиографияне) дөрес төзү дә бик мөһим. Эшне башкаруда файдаланылган хезмәтләр, чыганаклар алфавит тәртибендә бирелә, бер үк хәрефләрдән башланган автор фамилияләре, хезмәт исеме булганда, язудагы икенче, өченче хәрефләр белән бирелә, нәшер ителү урыны, нәшрият атамасы, бастырылган елы, битләр саны күрсәтелә. Моның билгеле бер калыплары (стандартлары) бар.

Мисал өчен, хезмәтнең (китапның) авторы берәү генә булганда: **Фәхретдинов Р.Г. Татар тарихы /Р.Г.Фәхретдинов. – Казан: Мәгариф, 1999. – 111 б.**

Китап авторы ике-өч булганда:

**Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле: Югары һәм урта уку йортлары өчен дәреслек / М.З.Зәкиев, Ф.С.Сафиуллина. – Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2002. – 407 б.**

Ә инде авторлар саны дүрт һәм аннан да күбрәк булганда:

**Татар теле: Татар урта гомумбелем мәкт. 6 нчы с-фы өчен д-лек / Д.Г.Тумашева, Ф.Ю.Юсупов, К.З.Зиннәтуллина һ.б.; К.З.Зиннәтуллина редакциясендә. Төзәт. һәм тулыл. 3 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2001. – 290 б.**

Төрле газета-журналлардан, җыентыклардан алынган мәкаләләрне бирүнең дә тәртибе бар. Мәсәлән:

**Хәким Р. Татар рухы // Казан утлары. – 2006. — № 11. – 128-132 б.**

Кушымтага теркәлгән өстәмә материаллар, схема-таблицалар, фотосурәтләр, карталар һ.б. фәнни эшне тулыландырып, аның кыйммәтен тагын да арттырып җибәрәләр.

Гадәттә, фәнни эшнең эчтәлеге хезмәтнең ахырында бирелә (битләре күрсәтелә). Әмма аны башта ук, нигездә, 3 нче биттә үк күрсәтү уңышлырак. Бу хезмәттән файдалануны күпкә җиңеләйтә.

**Фәнни язмаларның тел материалына** тукталып, түбәндәгеләрне күрсәтергә кирәк:

1. Фән теле ачык, аңлаешлы, төзек һәм камил булырга тиеш. Моның өчен телебезнең сүзлек хәзинәсеннән тулы һәм дөрес файдалана белергә, фикер сөрешенә туры килә торган лексик берәмлекләрне урынлы кулланырга, диалекталь, жаргон, вульгар сүзләрне файдаланмаска, сүзләрнең туры мәгънәсен бирергә, әдәби телнең лексик катламыннан аеруча актив кулланышта йөри торганнарын, синонимик вариантларның иң аңлаешлыларын сайлап алырга. Аеруча атамаларны (терминнарны) дөрес куллана белергә кирәк. Чөнки термин – төгәл фәнни атама, ул төшенчәнең эчтәлеген мөмкин кадәр тулы, ачык билгеләргә, кыска һәм туры мәгънәле булырга, шушы төшенчә өчен үз өлкәсендә аның башка варианты булмаска тиеш. Фикерне төгәл әйтеп бирүдә атаманың әһәмияте бик зур. Укучыларның фәнни язмаларында еш кына термин-атамаларны дөрес кулланмау, аларны мәгънә белдерә торган башка тел берәмлекләре белән бутау һәм орфографик хаталар белән язу очраклары күзәтелә. Боларны булдырмас өчен, төрле типтагы (аңлатмалы, тәрҗемәле, терминологик, орфографик һ.б.) сүзлекләргә мөрәҗәгать итәргә һәм гыйльми төшенчәләрне атый торган лексик берәмлекләрне дөрес кулланырга кирәк. Тарихи төшенчәләрне файдаланганда, Р.Ф.Галләмов тарафыннан төзелгән “Русча-татарча тарих терминнарының аңлатмалы сүзлегеннән” (Казан, 2006) файдаланырга мөмкин.

2. Укучыларның эшләрендә чагылыш тапкан төгәлсезлекләр морфология өлкәсенә дә карый. Аларга сүз формаларын дөрес кулланмау, кирәкмәгән кабатлаулар, фигыльнең заман формаларын бутау, исемнәрне килеш һәм тартым белән төрләндергәндәге ятышсызлыклар, зат-сан күрсәткечләрендәге буталчыклыклар, фигыльнең юнәлеш категорияләрен дөрес кулланмау, зат булмаган предметларны ачыклаганда, хәзерге заман сыйфат фигыльнең *-учы* / *-үче* төрләрен файдалану һ.б. керә.

Фәнни стиль өчен характерлы булган кайбер морфологик үзенчәлекләрне истә тоту мөһим. Болар:

1) фәнни стильдә фигыльләрнең *-л, -ыл, -ел* кушымчалы формаларына өстенлек бирелә;

2) үткәндә булган вакыйгаларны сурәтләгәндә, хикәя фигыльнең билгесез үткән заман формасы *(-ган/ -гән, /-кан / -кән)* үзен аклыйрак төшә;

3) фикерне конкретлаштыру, дәлилләү, йомгаклау һәм нәтиҗәләр чыгару өчен шактый гына кереш сүзләр һәм кереш сүз вазифасындагы ярдәмлекләр (димәк, ихтимал, беренчедән, икенчедән, шиксез, һичшиксез, ниһаять, минемчә, безнеңчә, гадәттә, йомгаклап әйткәндә, нәтиҗәдә, шулай итеп һ.б.) актив кулланыла;

4) аныклагычлар фикерне конкретлаштыруда, ачыграк бирүдә мөһим роль уйныйлар. Аныклаулы мөнәсәбәт, нигездә, исемнәр, фигыльләр зат алмашлыклары аша башкарыла һәм шуны белдерүче чараларга аныклау паузасы, аныклаучы теркәгечләр һәм теркәгеч сүзләр (ягъни, аеруча, бигрәк тә, мәсәлән, аерым әйткәндә, башкача әйткәндә, шул исәптән һ.б.) керә. Аныклаулы мөнәсәбәт булганда, аныкланмыш һәрвакыт алда, аныклагыч аннан соң урнаша. Мәсәлән: Әле бүгенгедәй хәтеремдә: эссе җәй көне, печән өсте иде (укучы язмасыннан).

3. Аңлаешлылык, төгәллек, тулылык, фикер сөрешендәге логик эзлеклелек фәнни язмаларның сөйләм төзелешенә бәйле. Бу яктан, хәзерге

әдәби телебез синтаксисының мөмкинлекләре гаять зур булса да, билгеле бер рамкаларга керергә туры килә.

Фәнни стиль өчен, нигездә, битараф рәсмилек хас. Шунлыктан тойгылы җөмләләргә караганда, тыныч хикәяләүгә зур урын бирелә. Җөмләдә сүзләрнең уңай тәртибе булырга тиеш. Сөйләм ачыклыгына комачаулык итә торган катлаулы төзелмәләрне артык еш куллану да үзен аклап бетерми, һичшиксез, укучының иҗади фикер йөртү сәләтен дә юкка чыгарырга ярамый. Җөмлә тәмамланган, фикерне дөрес бирерлек итеп төзелгән булырга тиеш.

4. Укучыларның эшләрендә бик күп пунктуацион хаталар да күзәтелә. Төп сәбәп – тыныш билгеләрен куюның төзелеш һәм мәгънәви (семантик) принципларын җитәрлек исәпкә алмауда. Бигрәк тә бу төр хаталар кызыл юл (яңа абзац), аерымланган хәлле гади җөмләләрне артык җәенкеләндерү, ияртүче кисәк белән ияртүче сүз арасындагы мөнәсәбәтләрне югалту, аныклагычлар, туры һәм кыек сөйләм белән бәйләнешле. Сөйләмдәге һәр тыныш билгесенең дә үз урыны барлыгын да истән чыгарырга һич ярамый, юкса зур төгәлсезлекләр килеп чыгарга мөмкин.

Йомгаклап шуны әйтергә мөмкин: бөтен эшләрне дә фәннилекнең аерым кысаларына кертеп, барысы өчен дә уртак нәтиҗә чыгару мөмкин түгел. Бу, беренчедән, фәнни стильнең мөмкинлекләрен күрмәү, төрләрен исәпкә алмау булыр иде (фәнни-популяр, фәнни-публицистик, фәнни-биографик һ.б.). Икенчедән, укучының мәсьәләгә иҗади якын килүен дә онытырга ярамый.

## Туган як тарихын өйрәнүдә төп чыганак буларак архив документлары

Тарихи чыганаклар – кешелек җәмгыяте үсешен чагылдыручы һәм аның фәнни танып белү нигезе, ягъни кешелек яшәешендә тупланган һәм күпьяклы җәмгыять тормышы турында мәгълүмат йөрткән барлык кыйммәтләр. Чыганакларга матди истәлекләр, сәнгатьле сурәтләү һәм график сурәтләү, язма истәлекләр һәм фонодокументлар керә. Тарихи чыганакларның иң әһәмиятлесе булып архив документлары санала.

Фәнни-эзләнү эшләрендә өйрәнелгән төп тарихи фактлар архив документларында чагылыш таба. Әмма архив документларын эзләү – бик катлаулы процесс; шуңа күрә күп вакыт сарыф ителеп тә, әйләнешкә бик аз күләмдә генә яңа чыганаклар кертелергә мөмкин.

Архив чыганакларын өйрәнә башлаганчы, тема буенча барлык фәнни әдәбият һәм бастырып чыгарылган чыганаклар белән танышу мөһим. Архив материалларын куллану өчен архив идарәсенең рөхсәтен алу мәҗбүри. Моның өчен гариза һәм фәнни-эзләнү эше белән шөгыльләнүче эшләгән (укыган) оешмадан махсус хат кирәк була (*Кушымта 1*).

*Искәрмә*: укучыларга архивның уку залында өлкәннәр кул астында гына шөгыльләнергә мөмкинлек бирелә.

Эшчәнлекнең башлангыч чорында архив хезмәткәрләренең киңәшләре аеруча әһәмиятле. Моннан тыш, уку залында саклanучы төрле белешмәләр һәм каталоглардан файдалану зарур. Тема буенча архив фондларын ачыклагач, тасвирламаларга мөрәҗәгать итәргә кирәк. Тасвирламалар – алар архив фонды саклау берәмлекләренең системалы исемлекләре. Шулай итеп, тасвирламаларда һәрбер эшнең (саклау берәмлекләренең) эчтәлегенә кыскача аңлатма бирелә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы баш архив идарәсенә Татарстан Республикасы Милли архивы, Татарстан Республикасы Тарихи-сәяси документларны саклау дәүләт үзәк архивы, Татарстан Республикасы аудио-визуаль документлар дәүләт үзәк архивы, Татарстан Республикасы аерым шәхесләргә бәйле документлар саклау үзәге, Татарстан Республикасы Дәүләт матбугат архивы, Татарстан Республикасы шәһәр һәм район хакимиятләренең архив бүлекчәсе керә (Бу турыда тулырак www. archive.gov.tatarstan.ru сайтыннан карарга мөмкин).

Россия Федерациясенең төбәкләр архивлары арасында иң зурысы – Татарстан Республикасы Милли архивы. Биредә ике миллионга якын эш саклана. Мәсәлән, төбәк авылларының революциягә кадәрге чорга караган тарихы турындагы мәгълүматларны түбәндәге фондлардан табарга мөмкин:

3 нче фонд (Казанская губернская казенная палата), 1-2 нче тасвирламалар; 204 нче фонд (Метрические книги мечетей (коллекция), 177 нче тасвирлама; 81 нче фонд (Казенная губернская земская управа), 2 нче тасвирлама; 2 нче фонд (Казанское губернское правление), 2, 14 нче тасвирламалар һ.б.

Архив фондының зур күләмдәге документлары республика һәм муниципаль музейларда һәм китапханәләрдә, фәнни оешмалар архивларында саклана. ТРның шәһәр һәм районнарында 45 муниципаль архив эшли[1]. Аларның иң зурлары – Әлмәт, Арча, Буа, Яшел Үзән, Чистай районнарында. Муниципаль архивлар фонды 903 меңнән артык саклау берәмлеген тәшкил итә.

Билгеле, эзләнү эше кирәкле архив материалларын җыю гына түгел, ә бәлки укучының аларны урынлы кулланып, анализ ясый белүе дә.

[1] См.: Справочник по фондам муниципальных архивов РТ: справочное издание. – Казань: Главное архивное управление при КМ РТ, 2010. – 720 с.

Тикшеренү эшендә архив мәгълүматларын кайдан алынуын төгәл һәм дөрес итеп бит астындагы төшермәләрдә күрсәтү зарур.

Мисал өчен:

ТР МА. 1 ф. 6 тасв. 326 эш. 52 б. (Татарстан Республикасының Милли архивы. 1 фонд. 6 тасвирлама. 326 эш. 52 б.)

Интервью алган очракта, ул материалларның чыганагы төшермәләрдә түбәндәгечә бирелә: (*интервью биргән кешенең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме*) белән интервью, (*аның туган җире, туган көне һәм елы*), (*интервью алынган көннең датасы*) // Архив (*авторның фамилиясе һәм инициалы*). Мәсәлән[1]:

Хезмәткә йомгак ясаганнан соң, библиографик исемлектә кулланылган чыганакларны һәм әдәбиятны күрсәтергә кирәк. Чыганакларның исемлеге түбәндәгечә төзелә:

Чыганаклар

1) бастырылмаган:

Татарстан Республикасы Милли архивы (ТР МА). 1 ф. 6 тасв. 326 эш, 327 эш.

Автор тарафыннан язылып алынган А.И.Иванованың истәлекләре (интервью алган көннең датасы һәм урыны).

Мәктәпнең сугышчан дан музее. Төп фонд, № 1 инв. А.И.Ивановның фронтта язган хатлары.

2) бастырылган:

История Казани в документах и материалах. XIX век. Книга III / Под ред. И.К. Загидуллина. – Казань: Главное архивное управление при КМ РТ, 2011. – 820 с.

[1] Дөлфәнурова Зөһрә Дөлфанур кызы белән интервью, ТР Минзәлә районының Бикбау авылында 1918 елның 12 февралендә туган. 2002 елның 2 октябре // И.И.Хәнипова архивы.

# Гаилә тарихын һәм төбәкнең тарихи шәхесләрен өйрәнү

## А) Шәҗәрәне ничек төзергә?

Укучылар яратып башкара торган эзләнү эшләренең берсе – гаилә, нәсел тарихын өйрәнү. Гаилә тарихын өйрәнүнең иң әһәмиятле өлеше – шәҗәрә төзү.

Шәҗәрә – нәсел-ыру тарихы дигән сүз. Татар халкы бик борынгы заманнардан ук нәсел-ыру тарихын язуга зур әһәмият биргән. Шәҗәрәләрдә бер нәселнең тарихы гына түгел, гомумән халкыбыз тарихы чагылыш таба. Шуңа күрә үз шәҗәрәңне белү, эзләү һәм тулыландыру – татар халкы тарихының сәхифәләрен тулыландыруга да өлеш кертә.

Шәҗәрә төзүне нидән башларга?

Шәҗәрә төзүче үзенең барлык туган-тумачаларын аерым-аерым ата һәм ана ягыннан тикшереп барларга, туганлык мөнәсәбәтләрен ачыкларга тиеш. Шәҗәрәнең төп чыганагы – гаилә, әти-әниләр, әби-бабайлар. Алар хакындагы мәгълүматларны өлкәннәрдән, ягъни әти-әниләр, әби-бабайларның үзләреннән, якын туган-тумачалардан сорашып җыйнарга мөмкин[1]. Борынгырак бабалар турындагы мәгълүматларны авыл зиратларындагы кабер ташларыннан табарга була. Язмалар гарәп графикасында булса, укый белүчене табарга кирәк. Шулай ук иң кыйммәтле чыганакларның берсе булган архив документларына да мөрәҗәгать итәргә мөмкин (метрикалар, ревизия материаллары һ.б. Бу турыда тулырак “Туган як тарихын өйрәнүдә төп чыганак буларак архив документлары” дигән бүлектән карагыз).

Шәҗәрәләргә кагылышлы материаллар авылның җир-су, урман исемнәренә бәйле риваятьләрендә дә сакланырга мөмкин. Шулай ук борынгы

[1] Бу турыда тулырак мәгълүматны Ф.Ислаевның “Я и моя родословная” (2009), Т.Биктимированың “Минем шәҗәрәм” (2000) китапларыннан алырга мөмкин.

кульъязмаларга нигезләнеп язылган мәгълүматларга да игътибарлы булырга кирәк.

Шәҗәрәгә кергән исемнәр, ата-ана, әби-бабаларның (шул исәптән шәҗәрә төзүченең үзенеке дә) кайсы авылда, шәһәрдә, кайчан, кайсы елда туулары, һөнәрләре турындагы мәгълүмат теркәлеп куелырга тиеш.

### Б) Төбәкнең тарихи шәхесләрен өйрәнү

Шәхес диюгә, татар халкының билгеле шәхесләре – Ш.Мәрҗәни, К.Насыйри, Г.Тукай, М.Җәлил һ.б. күз алдына килә. Бу олуг затлар турында күп хезмәтләр язылган булса да, яңа, төбәк мәгълүматлары табылган очракта, укучыларга шулар нигезендә фәнни-эзләнү эше язарга тәкъдим итәргә мөмкин.

Һәрбер төбәкнең – шәһәрме ул, авылмы, үзенең билгеле шәхесләре булган һәм бар.

Теге яки бу шәхес турында яза башлаганда, иң беренче аның тормыш юлына кагылышлы мәгълүматларны тупларга кирәк. Әгәр дә ул кеше исән икән, аның үзеннән материаллар алырга, истәлекләре булса, язмалары белән танышырга, тулы биографиясен, туган елын, көнен, туган җирен, яшәгән төбәге турында тулы истәлекләрен язып алырга кирәк.

Үзе исән булмаган шәхесләрнең туганнарыннан, аны белгән кешеләрдән хатирәләр туплау яхшы булыр. Җирле тарих өчен әһәмияте булган хезмәтен эзләп табарга тырышырга кирәк.

Төбәктән чыккан язучылар, рәссамнар һәм башка сәнгать әһелләре, шулай ук башка берәр тармакта аеруча зур уңышларга ирешкән шәхесләр тормышын өйрәнгәндә биографияләренә генә түгел, ә бәлки алар яшәгән чор белән бәйләнешенә, тарихи вакыйгаларның тормышларында чагылышына игътибар итәргә, тарихчы күзлегеннән чыгып анализ ясарга кирәк.

Язучы яки шагыйрьләрнең әсәрләре язылу тарихын өйрәнү дә кызыклы нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Шәхесләр турында тулырак мәгълүмат туплау өчен төрле чыганакларга – үзләренең хатирәләренә, көндәлекләренә, хатларга, алар турында башкалар тарафыннан язылган истәлекләргә мөрәҗәгать итү уңышлы була. Бу истәлекләрнең, мемуарларның язылу тарихын, ни өчен авторның ул эшкә алынуын ачыкларга тырышырга кирәк. Материалларның язылу датасын, урынын, авторның үзе сурәтләгән вакыйгаларда катнашу-катнашмавын ачыкларга тырышу мөһим.

Башка биографик чыганаклар белән чагыштырганда дөреслекне иң дөрес чагылдырганы – көндәлекләр. Шулай да көндәлекләрне өйрәнгәндә аларда искә алынган факт һәм вакыйгаларның дөреслеген тагын бер кат тикшерү, аларга карата үз фикереңне әйтә белү сорала.

Гаилә архивында сакланган башка шәхси документлар – туу турында таныклык, дипломнар, хезмәт кенәгәсе, рәхмәт хатлары, мактаулы исемнәр бирү турындагы таныклык, белешмә һ.б. лар ярдәмендә моңарчы тупланган биографик мәгълүматларның дөреслеген тикшерергә, дөресләргә мөмкин. Ләкин аларда да кайбер төгәлсезлекләр була алуын истә тотарга кирәк: төрле сәбәпләр белән кешеләр туган даталарын дөрес күрсәтмәскә, репрессиягә эләккән туганнарын атамаска мөмкиннәр. Шуңа күрә бары тик тулаем алып, комплекслы өйрәнгәндә генә чын дөреслекне ачыкларга мөмкин икәнлеген истән чыгармаска кирәк.

Шәхесләрнең тормышын өйрәнгәндә тагын бер алыштыргысыз материал – фотосурәтләр. Аларны гаилә альбомында, мәктәп музейларында табарга мөмкин. Бигрәк тә фотосурәтләрнең арткы ягына язылган язуга игътибар итәргә кирәк – аларда сезнең өчен бик кирәкле һәм кызыклы мәгълүматлар булырга мөмкин. Аларның күчермәләрен эшнең ахырында кушымта итеп китерергә була. Шәхесләр белән бәйле урыннар, йорты, чишмәсе һ.б. турында да язган очракта да аларның фотокүчермәләрен алырга һәм дөрес итеп тасвирлама бирергә кирәк.

Мәшһүр кешеләр, шәхесләр тормышын өйрәнгәндә тарихи документлар белән беррәттән, музей экспонатларына да мөрәҗәгать итү урынлы булыр. Чөнки музей экспонатлары теоретик материалны конкрет тормыш фактлары белән дәлилләргә мөмкинлек бирә.

Шунысын һәрвакытта истә тоту мөһим: эзләнү эшләрен үткәргәндә иң мөһиме – өйрәнгән шәхеснең гомумән тарихта тоткан урынын ачыкларга тырышырга кирәк.

## Тарихи һәм табигый һәйкәлләр

Тарихи-мәдәни мирас – искиткеч күпкырлы байлык. Аның төп нигезен сынлы һәм нәфис сәнгать әсәрләре, фәнни һәм техник объектлар, матди мәдәнияткә караган башка предметлар, тарихи вакыйгалар белән бәйләнешле, тарих, археология, архитектура, шәһәр төзелеше, нәфасәт, этнология, антропология күзлегеннән чыгып караганда кыйммәткә ия булган, теге яки бу төбәктә мәдәният барлыкка килү һәм аның үсешен ачыкларга мөмкинлек бирүче биналар тәшкил итә. Моннан тыш, табигый һәйкәлләр, кабер ташлары, мәдәни истәлекләр һ.б. туган як тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүдә әһәмиятле чараларның берсе булып тора.

Укучылар тарафыннан туган төбәктәге аз билгеле яисә моңарчы билгеле булмаган тарихи, табигый һәйкәлләрне барлау һәм таныту – фәнни-эзләнү эшенең актуальлеге һәм яңалыгы беренче чираттта шулардан гыйбарәт. Аларның халык авыз иҗатында яисә әдипләр иҗатында чагылыш табуын өйрәнүгә багышланган эшләр да укучыларда зур кызыксыну уята.

Табигый һәйкәлләр, ягъни фәнни, тарихи, экологик яктан әһәмияткә ия булган уникаль табигый объект һәм комплекслар саклауга мохтаҗ. Боларга шарлавыклар, метеорит кисәкләре, мәгарә, сирәк агачлар һ.б. керә. Кайвакыт табигать һәйкәлләренә зур күләмле территорияләрне – урман, тау сыртлары, елга ярлары һәм үзәннәрне дә кертеп карыйлар. Туган төбәктәге табигый

һәйкәлләрне табу һәм аларны өйрәнү, тарихларын яктырту, шуларга караган риваятьләрне туплау укучылар тарафыннан башкарыла торган фәнни-эзләнү эшләрендә иң уңышлы юнәлешләрнең берсе булып тора.

РФ законнары буенча күчемсез һәйкәлләрнең берничә төре билгеләнә. Болар:

• тарихи һәйкәлләр – халык тормышында мөһим роль уйнаган тарихи вакыйгалар, җәмгыять һәм дәүләт үсеше, фәнни-техник казанышлар, атаклы сәяси, дәүләт һәм хәрби эшлеклеләр, халык геройлары, фән, әдәбият, сәнгать әһелләре тормышы белән бәйләнешле биналар, корылмалар, истәлекле урыннар, аларның каберләре, Ватан сагында һәлак булганнарның күмелгән җирләре һ.б.;

• шәһәр төзелеше һәм архитектура һәйкәлләре – архитектур ансамбльләр һәм комплекслар, тарихи үзәкләр, мәйданнар, урамнар, борынгы шәһәр һ.б. торак урыннарның калдыклары; кешеләр яшәгән, сәнәгать, хәрби, табыну урыннары; табигый ланшафт, монументаль, сынлы, декоратив-гамәли, бакча-парк сәнгате һ.б.;

• археологик һәйкәлләр – шәһәрлекләр, курганнар, борынгы торак урыннары, ныгытмалар, каналлар, юллар, тау-ташлардагы сурәтләр, борынгы предметлар, каберлекләр, борынгы торакларның тарихи кыйммәткә ия булган катламнары һ.б.

Фәнни-эзләнү эшенең төп принцибы булып комплекслылык санала. Шунлыктан тарихи-мәдәни мирас комплекслы өйрәнелергә тиеш. Һәйкәлләрне саклауның зарурилыгын һәр кеше аңлаган очракта гына аның нәтиҗәсе күренәчәк. Хәзерге вакытта безнең авылларыбызда, районнарыбызда һәм хәтта шәһәрләребездә өйрәнелмәгән, ташландык хәлдә булган, онытылган күп кенә тарихи урыннар бар. Бу хәл килеп чыкмасын өчен, без һәйкәлләребезне белергә, исәпкә алырга, каталогын булдырырга тиеш. Әлеге өлкәдә фәнни эзләнүләр алып бару һәм ул тикшерүләрнең нәтиҗәсен халыкка җиткерү тарихи байлыкларны барлауда һәм кайтаруда зур һәм кирәкле эш булып тора.

Хәзерге вакытта татар халкының рухи мирасы белән матди мирасы бер-берсенә нык керешкән. Моннан тыш, гасырлар буенча тупланган барлык рухи байлыкларга ислам диненең дә йогынтысы зур. Татарстанда элек-электән барлыкка килгән изгеләштерелгән урыннар шактый. Бүген дә шәехләр каберлеге янында изге чишмәләр бар. Әмма бу төрдәге мирасыбызны саклау методикасы эшләнелмәгән. Тарихи һәм мәдәни һәйкәлләребез реестры юк, аларны төшендергән, бәясен күрсәткән китапларыбыз да юк диярлек. Халыкның аерым мирасы ташландык һәм югалу хәлендә. Бүгенге көндә тулысынча өйрәнелмәгән урыннар шактый. Аларны халыкка таныту, өйрәнү һәм саклау җитди мәсьәлә булып тора.

Укучы тарихи-мәдәни мирас белән бәйле теманы сайлаган вакытта, аны һәръяклап өйрәнергә, әлеге урынның халык һәм төбәк тормышында тоткан урынын күрсәтергә омтылырга тиеш. Шулай ук бу урынның әдәби әсәрләрдә яисә легендаларда телгә алынуына игътибар итәргә кирәк. Моның өчен табигый һәйкәлләргә сәяхәт ясала, өлкәннәр белән әңгәмәләр уздырыла, фәнни әдәбият һәм архив документларына мөрәҗәгать ителә. Бары тик бөтен мәгълүматларны өйрәнгәннән соң гына нәтиҗәләр чыгарырга мөмкин.

## Төбәкнең мәдрәсә, мәчет-мәхәллә тарихын өйрәнү

Билгеле булганча, ислам дине татар тарихы һәм мәдәниятенең аерылгысыз өлеше булып тора. Татар халкы элек-электән үк гыйлем алуга зур әһәмият биргән, үз хисабына мәктәп-мәдрәсәләр тоткан.

Һәр авылда диярлек бер яки берничә мәчет булып, алар янында һәрвакытта да мәктәп-мәдрәсәләр эшләп килгән. Шуңа күрә һәрбер татар авылының тарихы, иң беренче чиратта андагы мәчет-мәдрәсә һәм мәхәллә тарихы, шуларда гыйлем биргән мөгаллимнәрнең исемнәре белән бәйле. Татар дини уку йортларының 95% ы авылларда урнашканга күрә, мәктәп-мәдрәсәләр авыл мәхәлләсенең аерылгысыз өлеше булып торган. Туган

авылдагы мәдрәсә, мәчет, мәхәллә тарихын өйрәнү күпсанлы чыганаклар белән эшләүне таләп итә.

Эшне нидән башларга соң?

Беренчедән, авыл халкыннан, бигрәк тә аның иң өлкән кешеләреннән авылның элеккеге имамнары һәм мәчетләр, алар урнашкан урыннар турында сорашып, язып алырга кирәк. Төбәкнең дини тормыш тарихын барлау өчен район мөхтәсибәтенә, хәзер дә эшләп торган авыл мәчете булса, шунда мөрәҗәгать итәргә була.

Икенчедән, шактый гына мәгълүматлар тупланган энциклопедик (Татар энциклопедиясе), фәнни-популяр әдәбият, авыллар, мәктәп-мәдрәсәләр тарихына багышланган чыганаклар, вакытлы матбугатта дөнья күргән мәкаләләр белән танышу кирәк.

Әлеге юнәлештә иң бай мәгълүмат туплаган чыганаклар булып Шиһабетдин Мәрҗанинең “Мөстәфадел-әхбар”, Риза Фәхреддиннең “Асар” китаплары тора. Шулай ук XX гасыр башы татар вакытлы матбугаты – “Шура”, “Дин вә әдәп” һ.б. журнал һәм газета битләрендә дөнья күргән мәкаләләрне мәгълүмати чыганак буларак файдалану мөмкин (мәсәлән, төрле төбәкләрдән алынган хатларның ахырында бирелгән язучы исеме һәм яшәгән авылы турындагы мәгълүматлар һ.б.). Бүгенге заманда бай мәгълүмат чыганагы булган Интернетка мөрәҗәгать итү дә файдалы. Мисал итеп татар авылларына багышланган сайтларны туплаган ресурсны (http://awilim.ucoz.org/dir/19), шулай ук Бөтенроссия татар авыллары форумы (http://avillar.org/ru/forum) һ.б. сайтларны атарга мөмкин.

Татарстан Республикасының Милли архивында мәктәп-мәдрәсәләр тарихы белән бәйле бай фактик материал саклана. Мәсәлән, ТР Милли архивындагы Казан мәгариф округы инспекторларының татар мәктәпләре турындагы шикаятьләре (донослары), аларга беркетелгән мәчет каршында мөселман училищесы, мәктәбе, мәдрәсәләре һәм башка уку йортлары таблицалары теманы өйрәнүдә файдалы чыганак була ала. XIX гасырның 70

нче елларыннан башлап, мәдрәсә милке белән идарә итү кагыйдәләре проекты эшләнә башлый. Мәдрәсә ачуга рөхсәт сораган гариза белән беррәттән, мәгълүмати таблица (мәктәпнең исеме, төре (кадимиме яки җәдидиме), урнашкан урыны, ачылуга рөхсәт кайчан һәм кем тарафыннан бирелгәнлеге, укытыла торган фәннәр һәм дәреслекләр (авторы һәм башка мәгълүматлар белән) исемлеге, һәрберсенең белем цензы күрсәтелгән укытучылар исемлеге, укыту программалары турында белешмә, уку йорты җитәкчелегенең начар даны булу-булмавы турындагы һ.б. информация) бирелә. Китерелгән мәгълүматларда еш кына әлеге уку йортының мәчет төзелгәч, мәктәп ачу яки укытуга рөхсәтсез үк эшли башлавы турында әйтелә. Вакыт үтү белән әлеге таләпләргә түбәндәгеләре дә өстәлә: уку йортына караган халык һәм мәктәп яшендәге балалар саны, уку йорты белән аңа иң якын урнашкан рус авылы арасындагы ераклык, һәм иң кызыгы, күрше авыл христиан руханиларының фикере. Авылларның мәчет, мәхәллә һәм мәдрәсә тарихын өйрәнгәндә әлеге документлар кыйммәтле чыганак була ала.

Гомумән алганда, төбәкнең, яки авылның мәдрәсә, мәчет-мәхәллә тарихын өйрәнү өчен мәгълумат туплаганда, игътибарны түбәндәге мәсьәләләргә юнәлтергә кирәк булыр:

1) Мәчет, мәдрәсә тарихына караган белешмәләр: кайчан, кем тарафыннан салынган, Совет чорындагы халәте, яңадан торгызылу тарихы, бүгенге хәле.
2) Авылда имамлык вазифасын башкарган дин әһелләренең исемлеген төзү, алар арасында булган данлыклы хәзрәтләрнең тормыш юлын һәм эшчәнлеген ачыклау. Шулай ук авылның мәшһүр абыстайларын әйтеп китү дә урынлы булыр.
3) Мәдрәсәдә эшләүче мөдәррисләрнең исемлеген булдыру, аларның кайда укыганлыгын, шәкертләрен ачыклау.

4) Мәдрәсәдә укытылган фәннәр, кулланылган китаплар исемлеген булдыру.

5) Совет чорындагы мәктәп тарихын яктырту.

6) Бүгенге көндә авылдагы мәчетләр саны, аларның торгызылу тарихы, иганәчеләр, төзелеш эшләрен оештырып җибәрүчеләр турында мәгълүмат, имам вазифасын башкаручы, аның ярдәмчеләре һ.б. турындагы мәгълүмат.

## Туган як тарихын өйрәнүдә топонимиканың роле

Туган як тарихын өйрәнгәндә ономастика (ялгызлык исемнәре турында фән), аерым алганда аның топонимика дип аталган тармагы, махсус игътибарга лаек. Топонимика (грек. topos – урын һәм onyma – исем) – географик атамаларны (топонимнарны), аларның мәгънәләрен, килеп чыгышын, барлыкка килү үзенчәлекләрен, шулай ук тарихи үсеш-үзгәрешләрен өйрәнүче фән. Топонимика, этнография, география, археология, мифология кебек фәнни өлкәләр белән тыгыз бәйләнештә булып, тарих фәне өчен кызыклы һәм кыйммәтле чыганак тәшкил итә. Ялгызлык исемнәренә, аларның төп – номинатив мәгънәләреннән тыш, тарихи мәгънә дә салынган булырга мөмкин. Мисал өчен, җирле халык һәм кабилә атамалары; теге яки бу авылга яисә шәһәргә нигез салучы, беренче күчеп килүчеләрнең исемнәре; җирле халыкның социаль-икътисади үзенчәлекләренә караган аерым мәгълүматлар һ. б. Болар барысы да туган як топонимикасын мәктәптә өйрәнүнең әһәмиятен күрсәтә, әлеге фән тармагын үзләштерү укучыларның белем дәрәҗәсен күтәрү, аларда патриотик хисләр тәрбияләү, үз халкыңның тарихына карата хөрмәт тәрбияләү кебек максатларга ирешү өчен ярдәм итә.

Топонимика өлкәсенә караган фәнни-эзләнү эшләрен уңышлы башкаруның алшарты укучының фәнни һәм методик әдәбият белән яхшы

таныш булуына бәйле. Бу, үз чиратында, тикшеренүче баланың топонимика буенча махсус кулланмалар, фәнни-популяр әдәбият, топонимик һәм терминологик сүзлекләр, энциклопедияләр белән якыннан таныш булуын, шулай ук Татарстан Республикасы топонимиясенә багышланган махсус монографияләрне өйрәнүен күз алдында тота (Гарипова Ф.Г., Саттаров Г.Ф. һ.б. хезмәтләре).

Топонимик күренешләрне өйрәнү методологиясенә килгәндә, тарихи методка өстенлек бирергә кирәк, ул исем-атамаларның килеп чыгышын җәмгыять тарихы белән тыгыз мөнәсәбәттә тикшерә. Фәнни-эзләнү эшләрен башкарган вакытта архив материалларын, картографик чыганакларны куллану, эзләнү темасына караган мөһим мәгълүматларны таба һәм анализлый белү мөһим. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: топонимик эзләнүләр барышында халык авыз иҗаты материалларын, авыл аксакаллары арасында сакланган хикәятләрне дә файдаланырга мөмкин. Әмма теге яки бу атаманың килеп чыгышы хакында төрле версияләр яшәгәндә, укучы топонимик легенда һәм риваятьләр белән бергә фәнни таләпләргә җавап бирә торган версияләрне дә аңлатырга, өйрәнә торган проблема буенча нәтиҗәләр чыгара белергә тиеш.

Туган як топонимикасын өйрәнгәндә фәнни-эзләнү эшләренең төп тематикасы түбәндәге проблемаларга карарга мөмкин: атамаларның тарихы, барлыкка килү тенденцияләре, этимологиясе, структур-семантик анализы. Шулай ук авыл-шәһәрләрнең исемнәрен үзгәртү мәсьәләләре, атамаларның теге яки бу вакыйгалар, күренешләр, күренекле кешеләр белән бәйле булулары, географик атамаларда әлеге җирлектә яшәүче халыкның социаль-мәдәни тормышы чагылышы кебек темалар да кызыксыну уятырга мөмкин. Алга таба мондый төр эшләр укучыларда тикшеренү эшчәнлегенә кирәкле күнекмәләр формалаштыру белән бергә туган як тарихына кагылышлы яңа сәхифәләр дә ачарга мөмкин.

## Туган төбәкне өйрәнү материалы буларак фольклор

Халык авыз иҗаты бик борынгы заманнардан бирле халык тарихының үзенчәлекле юлдашы булып тора. Фольклор әсәрләрендә халыкның тарихи үсеш юлында алган тормыш тәҗрибәсе һәм милли традицияләре чагыла. Алар буыннан-буынга, телдән-телгә күчеп, гасырлар буе яшәп килгәннәр.

Җирле төбәктәге фольклор әсәрләре жанрлар төрлелеге белән характерлана. Бигрәк тә монда риваятьләр, мөнәҗәтләр, бәетләр, тарихи һәм лирик җырлар, йолалар зур урын алып тора. Әлеге әсәрләр халык тарихы, аның тормышында сизелерлек эз калдырган әһәмиятле тарихи вакыйгалар, конкрет тарихи шәхесләр турында мәгълүмат бирә. Шуңа күрә алар әһәмиятле тарихи чыганак ролен үтиләр.

Бүгенге көндә халык авыз иҗаты әсәрләре фәнни яктан күпмедер дәрәҗәдә тикшерелгән булса да, җирле фольклор аз өйрәнелгә. Шулай да соңгы вакытларда билгеле бер төбәкнең халык авыз иҗаты әсәрләрен туплау һәм өйрәнүгә күбрәк әһәмият бирелә башлады. Әмма җирле фольклорны өйрәнгәндә алар белән тирәнтен эшләнелми, бары тик гомуми күзаллау белән генә чикләнелә.

Җирле фольклор буенча фәнни-тикшерү эшен оештырганда фәннилек, иҗадилык һәм эзләнүчәнлек таләп ителә. Иҗади һәм фәнни характердагы эшләр фән белән кызыксынуны арттыра, логик фикерләү сәләтен үстерә, төрле чыганаклар белән мөстәкыйль рәвештә эшләргә өйрәтә.

Җирле халык авыз иҗаты буенча фәнни-тикшеренү эшен оештырганда фәнни монографик хезмәтләрне, библиографик чыганакларны, вакытлы матбугатны, төрле кулъязма материалларны өйрәнүдән башлау әһәмиятле. Чөнки фәнни чыганакларга мөрәҗәгать итәргә өйрәнү, фәнни материал һәм сүзлекләр белән эшләү җирле халык авыз иҗатын фәнни яктан өйрәнүгә юл күрсәтә.

Фәнни-эзләнү эшенең икенче этабы булып, җирле халыкның, өлкән яшьтәге кешеләрнең истәлекләрен җыю, туплау тора. Чөнки җирле төбәккә караган фольклор әсәрләре халыкның хәтерендә, өлкән буын кешеләренең истәлекләрендә саклана.

Җирле фольклор әсәрләрен өйрәнүнең өченче этабы – фәнни-теоретик фикерләрне формалаштыру, анализлау, тикшерелгән материалларны системага салу.

Халык авыз иҗаты әсәрләренең һәр төренең үзенә генә хас булган үзенчәлекләре бар. Шуны истә тотып, әсәрне өйрәнгәндә аның жанрына карап, махсус алымнарга карап эш ителә. Риваятьләрне, бәетләрне, мөнәҗәтләрне фәнни яктан өйрәнгәндә ул кайсы чорга карый, нинди вакыйгалар сурәтләнгән, әлеге вакыйгалар сезнең төбәккә генә хасмы, фәнни яктан өйрәнелгәнме кебек сорауларга җавап эзләү әһәмиятле.

Төбәкнең йола фольклорын өйрәнү дә анда яшәүче халыкның тарихын ачыклауда мөһим урын алып тора. Фәнни яктан ел фасылларына һәм гаилә-көнкүреш фасылларына бүленгән йолалар әлеге төбәктә сакланганмы, ниндиләре сакланган, хәзерге вакытта алар кулланыламы, аерым төбәккә генә хас йолалар бармы икәнлеген ассызыклап үтү мөһим шарт.

Җирле фольклорны өйрәнгәндә үз төбәгенә генә хас халык авыз иҗатының кабатланмас матурлыгын күрсәтү, бай тарихын сөйләү иҗади актив эш таләп итә.

## Тәкъдим ителгән әдәбият


1. Бәширова И.Б. Хәзерге татар әдәби телендә фәнни әдәбият стиле: гомуми мәгълүмат / И.Б. Бәширова // Фән һәм тел. – 2000. – №3. – Б. 12-15.
2. Беляев А.Б. Историческая генеалогия татарского народа. Родственные династии и их роль в истории, семьи, нации и государства / А.Б.Беляев. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. – 763 с.
3. Биктимирова Т.Ә. Минем шәҗәрәм / Т.Ә.Биктимирова. – Казан: Мәгариф, 1999. – 32 б.
4. Галләмов Р.Ф. Русча-татарча тарих терминнарының аңлатмалы сүзлеге / Р.Ф.Галләмов. – Казан: Мәгариф, 2006. – 224 б.
5. Гарипова Ф.Г. Татарстан гидронимнары сүзлеге / Ф.Г.Гарипова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 224 б.
6. Ибраһимов С.М. Синтаксик стилистика / С.М.Ибраһимов. – Казан: Ун-т нәшр., 1989. – 150 б.
7. Ислаев Ф.Г. Я и моя родословная : уч. пособие для учащихся ст. кл. сред. общеобразоват. шк. / Ф.Г. Ислаев – Казань : Магариф, 2009. – 150 с.
8. Кожина М.Н. О речевой системности научного стиля сравнительно с некоторыми другими: Учеб. пособие / М.Н. Кожина – Пермь, 1972. – 386 с.
9. Курбатов Х.Р. Татарская лингвистическая стилистика и поэтика / Курбатов Х.Р.- М.: Наука, 1978. – 218 с.
10. Курбатов Х.Р. Татар теленең синтаксис һәм стилистика мәсьәләләре / Х.Р. Курбатов. – Казан: Таткнигоиздат, 1956. – 176 б.

11. Курбатов Х.Р. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы / Х.Р.Курбатов.- Казан: Мәгариф, 2002. – Б. 28-29.

12. Национальный архив РТ: Фонды Попечителя казанского учебного округа (ф. 92), Директора народных училищ Казанского учебного округа по Казанской губернии (ф.160), Казанского губернского жандармского управления (ф.199) и др.

13. Писцовая книга Казанского уезда 1602-1603 годов. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1978.

14. Писцовая книга Казанского уезда 1647-1656 годов / И.П.Ермолаев, Д.А.Мустафина. – М., 2001.

15. Саттаров Г.Ф. Ни өчен шулай аталган? / Г.Ф.Саттаров. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. – 128 б.

16. Саттаров Г.Ф. Мәктәптә туган як ономастикасы / Г.Ф.Саттаров. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 208 б.

17. Саттаров Г.Ф. Атамалар дөньясына сәяхәт / Г.Ф.Саттаров. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 240 б.

18. Сафиуллина К.З. Методические рекомендации по использованию литературного отдела Госмузея ТАССР во внеурочной работе / К.З.Сафиуллина – Казань: ТИУУ, 1976. – 16 с.

19. Сафиуллина К.З. Некоторые формы и методы совместной работы школы и музея по патриотическому и интернациональному воспитанию учащихся подростков / К.З.Сафиуллина. – Ульяновск, 1978. – 92 с.

20. Сафиуллина Ф.С. Фәнни стиль үзенчәлекләре / Ф.С. Сафиуллина // Фән һәм тел. – 1997. – №1. – Б. 62-66.

21. Справочник по фондам муниципальных архивов РТ: справочное издание. – Казань: Главное архивное управление при КМ РТ, 2010. – 720 с.

22. Татар халкы тарихы һәм мәдәнияте (Борынгы заман һәм урта гасырлар): Татар телендә белем бирү мәктәбенең 5 нче сыйныфы өчен уку әсбабы / Фәнни ред. М.М.Гибатдинов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 199 б.

23. Татар халкы тарихы һәм мәдәнияте (Урта гасырлар): Татар телендә белем бирү мәктәбенең 6 нчы сыйныфы өчен уку әсбабы / Фәнни ред. М.М.Гибатдинов.. – Казан: Татар. кит. нәшр.,2012. – 215 б.

24. Фасеев Ф.С. Татар телендә терминология нигезләре / Ф.С. Фасеев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. – 198 б.

25. Фольклор жанрларын анализлау / Ред. Р.З. Шәрәфетдинова. – Казан: Казан университеты нәшрияты, 1986. – 128 б.

26. Фольклор жанрларын система итеп тикшерү. – Казан: Казан университеты нәшрияты, 1987. – 162 б.

27. Хаков В.Х. Татар әдәби теле ( стилистика ) / В.Х. Хаков. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – Б. 255-266.

27. Хангилдин В.Н. Татар теле культурасының кайбер мәсьәләләре / Төз. Ганиев Ф.Ә. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1976. – 96 б.

***

1. Әхмәтҗанов М.И. Татар шәҗәрәләре: 1 т. / М.И.Әхмәтҗанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – 407 б.

2. Әхмәтҗанов М.И. Меңъеллык татар нәселе: татар шәҗәрәләре һәм этник тарихыбызга бер караш / М.И.Әхмәтҗанов. – Казан: Мәгариф, 2001. – 63 б.

3. Әхмәтҗанов М.И. Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы / М.И.Әхмәтҗанов. – Казан: Мәгариф, 2002. – 343 б.
4. Гаспринский И. Русское мусульманство. Мысли, заметки и наблюдения мусульманина / И.Гаспринский. – Симферополь, 1881.
5. Бакиров М.Х. Татар фольклоры: югары уку йортлары өчен дәреслек / М.Х.Бакиров. – Казан: Мәгариф, 2008. – 358 б.
6. Балалар фольклоры һәм җырлы-сүзле йөз төрле уен / Төз. Н.Исәнбәт. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1984. – 486 б.
7. Баязитова Ф. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары / Ф.Баязитова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 158 б.
8. Гарипова Ф.Г. Елгалар дөньясына сәяхәт / Ф.Г.Гарипова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 63 б.
9. Гарипова Ф.Г. Исемнәрдә – ил тарихы / Ф.Г.Гарипова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. – 264 б.
10. Гарипова Ф.Г. Авылларны сөям җаным-тәнем белән: Фәнни-популяр очерклар / Ф.Г.Гарипова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. – 144 б.
11. Гарипова Ф.Г. Татарстан гидронимнары сүзлеге / Ф.Г.Гарипова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 224 б.
12. Гарипова Ф.Г. Авыллар һәм калалар тарихыннан / Ф.Г.Гарипова. Беренче җилд. – Казан: Матбугат йорты, 2001. – 720 б.; Икенче җилд. – Казан: Матбугат йорты, 2003. – 720 б.
13. Горохов В.М. Реакционная школьная политика царизма в отношении татар Поволжья / В.М.Горохов. – Казань, 1941.- 258 с.

14. Загидуллин И.К. Татарская школа и русификаторская политка царизма во второй половине XIX в. / И.К.Загидуллин // Народное просвещение у татар в дооктябрьский период. – Казань, 1992. – С.72.

15. Ибрагимов Д.И. «Мы даем возможность посмотреть из настоящего в прошлое и будущее» / Д.И.Ибрагимов // Казанские истории. – 2006. – № 9. – С. 37.

16. Коблов Я.Д. Конфессиональные школы казанских татар / Я.Д.Коблов. – Казань: Центральная типография, 1916. 119 с.

17. Коблов Я.Д. Мечты татар-магометан о национальной общеобразовательной школе / Я.Д.Коблов. – Казань: Типо-лит. Имп. Казанского ун-та, 1908. – 20 с.

18. Мәрҗани Ш.Б. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр) / Ш.Б.Мәрҗани. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 415 б.

19. Татар халык иҗаты: Хрестоматия / Төз. Урманче Ф., Миңнуллин К. – Казан: Мәгариф, 2004. – 479 б.

20. Татар балалар фольклоры / Төз. Ягъфәров Р. – Казан: Раннур, 1999. – 352 б.

21. Татар энциклопедиясе. 6 томда. – Казан: ТЭИ, 2008 –

22. Уразманова Р.К. Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре / Р.К.Уразманова. – Казан, 1992.- 96 б.

23. Урманче Ф. Татар халык иҗаты / Ф.Урманче. – Казан: Мәгариф, 2005 – 383 б.

24. Фәхреддин Р. Асар. Дүрт томда / Р.Фәхреддин. – Казан: Рухият, 2006 – 2010.

25. Фукс К. Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. Краткая история города Казани. Репринтное воспроизведение / К. Фукс. – Казань, 1991. – 209 с.

**Кушымта**

РӘСМИ БЛАНКТА

№ ____________от ___________________

Директору

Национального архива

Республики Татарстан

**Л.В. Гороховой**

**Уважаемая Людмила Васильевна!**

(*Наименование организации*) просит Вас разрешить пользоваться фондами Вашего архива *(занимаемая должность, полностью фамилия, имя, отчество пользователя)* для сбора материалов по теме: *(Название темы).*

Директор Подпись